**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2020елның19 августы 1661номер

**КАРАР**

**Лаеш муниципаль районы Имәнкискә авылында “Именьковский» ДНТ өчен газүткәргечтән ф159 нчы тоташтыру” "объекты буенча территорияне межалау проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линияле объектлар төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, 2020елның 13 гыйнварендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чыршы авыл җирлеге территориясендә урнашкан Лаеш муниципаль районының Имәнкискә авылындагы «Именьковский» ДНТ өчен газүткәргечтән ф159 нчы тоташтыру” обьекты буенч территорияне межалау проектын расларга.

2. Әлеге карарны «Кама ягы» «Камская новь» район газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб - адресы һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Лаеш муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.П. Шитов**